# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“10” ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 10 ноябрендә «Сез 2020 елда Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Ябынчы авылы зиратын чистарту өчен чыгымнар тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 3 (өч) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 3 (өч) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 3 (өч) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2020 елда Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: “Ябынчы авылы зиратын чистарту өчен чыгымнар тоту” мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Низамиев